

Үз эшенә шулкадәр бирелеп, чын күнелдән тырышып һәм яратып, жанын-тәнен биреп хезмәт итүче кешеләргә ихластан сокланам.
Рәйсә Хәмзә кызы Саитова 1941нче елнын 22нче июнендә иртәнге 4 сәгатьтә Кадошкино (элекке Инсар) районы Латышовка авылында доньяга килә. Әтисе Үмәр улы Хәмзә кибеттә сатучы булган, ә әнисе, аш-суга бик унган Исмаил кызы Мәрзыя, колхоз бридасында тырышып эшләгән. Алар оч бала тәрбияләп vстергәннәр: олылары Рива - Ләмберә районы Татар Тавла авылы мәктәбендә укытучы булып хезмәт иткән, оченчеләре- Равил туган авылында гаиләсе белән матур гына яшәгәндә яшьли vлеп китә. Рәйсә - уртанчы бала булып vсә.       Хәмзә кызы Рәйсә туган авылы топ мәктәбен тәмамлап, Большие Поляны ур- та мәктәбендә укый. Шул вакыт Иса малае Әббәс Исхак улы Кильдеев Рәйсәгә kvз салып йори. Әббәс армиядән ике ел хезмәт итеп кайткач, алар ойләнешәләр. Ә шул вакыт мәктәп тәмамлаган Рәйсә Инсар шәһәре фабрикасында эшли торган була. Матур гаилә корып ике бала, Ильдар белән Ильданны vстергән чакта, Рәйсә Хәмзә кызы Большие Поляны авылы «Победа» колхозы бригаларынын берсенә эшкә чыга. Ә инде оченче баласы – кызы Эльмира тугач, фермага сыер савучы булып эшкә урнаша.



Авыл жирендә, нигездә, ботен кеше дә терлек асрый, шуна kvрә мал-туар карау серләренә балачактан ук ойрәнеп vсәләр. Рәйсә апа сыер савуны беренче тапкыр кеп-кечкенә чагында, Латышовкада vз сыерларын әнисе сауганда kvрә, ә аннары vзе дә сава башлый. Хәзерге яшьләрнен бер дә авыл жирендә каласылары килми, дип юкка

әйтәләр. Бу мәсьәләдә кvп нәрсә гаиләдәге тәрбия дән тора. Терлекләрне карау гына тvгел, аларны анлый да белv авыл кешеләренә ана соте белән керәдер, могаен. Малкай нинди генә чыгымчылый торган булмасын, Рәйсә апа анын жаена тошә, шуна кvрә сыер да сотен жәлләми бирә.
Авыр ферма эшенә килгән яшь хатын, олкән остазларына карап, тәжрибә туплый. Кулда 40 сыерга кадәр саугач, машина белән саву операторы эшен дә булдыра ул. Хезмәт жинелләрдән тvгел, әмма әйбәт тvләнә.Осталыкнын нигезе - тырышлык, диләр.  Эшен намус белән башкара, кушканнарны жиренә житкереп vти. Бик жаваплы, тырыш сыер савучы була заманында, комплекста ин яхшы эшчеләрнен берсе дә. Һәр елны әйбәт хезмәт кvрсәткечләре очен бvләкләнә. Совет хатын-кызы – хезмәт кешесе, ана һәм герой, тирән хөрмәткә лаек ул.
Рәйсә Хәмзә кызы унган хужабикә дә. Ул бер ойдә кайнанасы һәм каенатасы белән 40 ел бергә яши. Авыр хезмәттә булуына карамастан, ой эшләрен барысын да vзе башкара. Үзләренен шәхси хужалыкларында да мал-туарны кvпләп асрыйлар.
Ике малаен армиягә хезмәткә озата. Шул арада ире Әббәс бакыйлыкка кvчә. Авырлыктан курыкмаган язма героебыз оч баласын «аяк остенә бастыра». Ул балаларына һәрвакыт: «Кеше буласыгыз килсә, зур укулар укыгыз»,- дип тәрбияли. Тормыш ул гел яхшылыктан гына тормый, яман вакытлар да була. Шулай, улы Ильдар авырып vлә. Кара кайгысын уртаклап, берvзен генә калдырмас очен, улы Илдан белән кызы Эльвира Рәйсә апанын оныкларын чиратлашып, янында торырга калдыра башлыйлар. Илданы хәзер гаиләсе белән Финляндиядә яшиләр. Анын vз фирмасы бар, шунда эшли. Кон саен әнисенә шалтыратып тора. Илданнын кызы Алина - аналитик, анын ире Иса - аудитор булып хезмәт итәләр; әбәйләренен хәлен һәр кич сорашып торалар, онытмыйлар. Ә Эльвирасы Саранскта гаиләсе белән яши, тормыш иптәше белән оч бала тәрбиялиләр. Улы Артуры Казанда стоматологка ординатура бетерә, Сашалары МГУда укый, ә кечкенәләре, Светалары – 7нче сыйныф укучысы. Бик матур рәсем ясый.
Рәйсә Хәмзә кызы Кильдеева бvгенгә бик бәхетле кеше. Ул киленнән дә, киявдән дә унды. Кияве Александр, Рәйсә апанын кечкенә ое янына, барлык удобствалар белән, яна йорт салган - картлык конендә рәхәтләнеп яшә, ди. Атна саен анын ое тулы кунак- лар: мунчасы яккан, пәрәмәчләре, бәлеше пешкән. Балалары, оныклары, кvршеләре белән бергә, кунак булалар. Ул барчасын якты чырай, ачык кvнел белән каршы ала. Аны кечкенә балалар да бик ярата. Рәйсә Хәмзә кызы яшьләр янында vзе дә яшәреп китә.

**Наилә НАСЫРОВА**